***Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге “Балачак” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе***



# Чишмә башы

**Апрель, 2025 ел**



**2025 ГОД ЗАЩИТНИКА ОТЕЧЕСТВА**

**80 ПОБЕДА!**

***Ата-аналар һәм балалар өчен кызыклы мәгълүматлар***

## *Апрель аена истәлекле даталар*

**1** – Көлке көне.

**2** – Халыкара балалар китабы көне.

**7** – Бөтендөнья сәламәтлек саклау көне.

**12** – Бөтендөнья авиация һәм космонавтика көне.

**18** – Халыкара һәйкәлләр һәм тарихи урыннар көне.

**22** – Бөтендөнья Җир көне.

**26** – Туган тел көне. Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайны искә алу көне.

**29** – Халыкара бию көне.

**30** –Янгын күзәтчелеге көне



## *Апрель аена халык сынамышлары*

Апрельдә карлыгачлар килмәсә, салкын язга.

Апрель яңгырлы булса, гөмбә уңар;

Апрельнең алтысында торна кычкырса, ел яхшы килә.

Ай башында яшен яшьнәсә, җәй җылы килер һәм чикләвек мул булыр;

Апрельдә көндез кызу, төнлә салкын булса, җылы җәй юрыйлар;

Ай ахырында төннәр йолдызлы булса, уңыш уңар;

Апрельдә каен суы күп акса, җәй яңгырлы килер;

Апрель артык җылы булса, май салкын, җилле булыр



**«ЭКО ЯЗ 2025»**

**2025 елның 1 апреленнән санитар-экологик икеайлык кысаларында Татарстан Республикасында «ЭКО ЯЗ 2025» республика конкурсы башланып китте, безнең балалар бакчасы бу акциягә бик теләп кушылды.**

**1 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ «Канатлы дусларга ярдәм ит!»**


#ЭКО ЯЗ бәйгесенең 1нче атнасы «Канатлы дусларга ярдәм ит» девизы астында узды (сыерчык оялары, җимлекләр ясау, шулай ук аларны элеп кую, 1 апрельдә Халыкара кошлар көнен билгеләп узу). Бу атна кысаларында тәрбияләнүчеләр җылы яклардан кайткан кошларга уңайлы оялар һәм җимлекләр булдыру процессына актив кушылдылар. Әти - әниләр белән дә эшчәнлек оештырылды.

Сыерчык ояларын һәм җимлекләрне элү балалар һәм өлкәннәр өчен кызыклы чара. Җимлекләргә ашарга салу, кошлар өчен уңайлыклар тудыру, балаларга да, әти - әниләргә дә тәрбия бирә. Бу процесс кошларның экосистемадагы роле һәм аларны саклау кирәклеге турында танып-белү әңгәмәләре белән үрелеп барды.

Сыерчык оялары һәм җимлекләр ясау һәм элү белән беррәттән, Халыкара кошлар көненә багышланган тематик чаралар да үткәрелде.

#ЭКО ЯЗ бәйгесе-экологик культураны формалаштыруда һәм биотөрлелекне саклау проблемаларына игътибарны җәлеп итүдә мөһим адым.








**2 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ «Без аерым җыю өчен»**

**( макулатура, пластик капкачлар , батарейкалар җыю, җыю пунктларына иске кием тапшыру һ. б.)**

Безнең балалар бакчасында «Макулатура тапшыр - агачларны сакла!»,«Игелекле капкачлар» дигән экологик акцияләр узды. Бакчабызда макулатура һәм пластик капкачлар җыю почмагы булдырылды. Бүгенге көндә экология, урманнарны кисүдән саклау, аны кеше ихтыяҗларына яраклаштырып юк итү мәсьәләләре тагын да зур әһәмияткә ия. Бу фикерне мәктәпкәчә яшьтәге балаларга җиткерү бик мөһим. Төркем тәрбиячеләре әңгәмә үткәрделәр: макулатура ни өчен җыярга кирәк, аны эшкәртүдән соң нәрсә эшләргә була, бу урманнарны кисүдән сакларга ярдәм итәчәк. Җыелган макулатураны планетабызның тулы бер «яшел резерв»ын саклап, кабат кулланырга мөмкин. Акция идеясен хуплаган, макулатура һәм капкачлар җыю процессына, актив кушылган балаларга һәм ата-аналарга рәхмәт әйтәсе килә.

#ЭКО ЯЗ -2025

#сбормакулатуры







**3 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ «Җиргә бакча бүләк ит»**

Татарстанга бергәләп яңа бакча бүләк итик - агачлар, куаклар һәм башка яшеллекләр утыртыйк. Ә безнең бакчабызда бу эш тирә-якта булган агач һәм куакларның төпләрен йомшарту, агарту эшеннән башланып китте. «Җиргә бакча бүләк ит» экологик марафоны кысаларында балалар ата-аналар белән берлектә яшел үсентеләр: агачлар – куаклар утырттылар. Балалар һәм өлкәннәрнең уртак эшчәнлеге ярдәмендә һәркем территорияне яшелләндерүгә үз өлешен кертте. Балалар зурларга су ташырга, үсентеләрне тотып торырга булыштылар. Агач утырту юлы белән безнең тәрбияләнүчеләр, ата-аналар һәм педагоглар авылны яшелләндерүгә көчләреннән килгәнчә өлеш кертәләр, чөнки утыртылган бер агач һәр кечкенә баланың йөрәгендә озакка истә калыр һәм сакланыр. Агачлар үсеп китәрләр һәм тиздән куе яфракларын кыштырдатып, үзләренең нәни балаларын искә төшерерләр дип өметләнәбез .




**4 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ «Синең гамәлләрең»** (территорияләрне җыештыру чараларын үткәрүгә юнәлдерелгән). Иң беренче балалар бакчасы коллективы бакча территориясен җыештырудан башлады. Барысы да бакча территориясен бик теләп тәртипкә китерделәр: чүп-чарны җыйдылар, үз участокларын себерделәр. Ике-өч сәгать эчендә уртак көч белән бакча территориясе күзгә күренеп үзгәрде. Мондый эшләр балаларга һәрвакыт уңай йогынты ясый, гади хезмәт күнекмәләренә, тәртипкә өйрәтә. Бакча территориясен җыештыру – ул территорияне төзекләндерү һәм чистарту гына түгел, балаларны бердәмлеккә өйрәтү мөмкинлеге дә булып тора. Балалар бакчада гына түгел, үзләренең каралты-кура, йорт тирәләрен чистарту эшендә актив катнашалар. Чиста территория тирә-юньдәгеләрнең күзләрен шатландыра.



## «Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның туган көне»



Безнең балалар бакчасында бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның туган көненә багышланган чара узды. Кичә барышында шагыйрьнең тормыш юлы искә төшерелде. Балалар Тукайның «Кәҗә белән сарык» әкиятен сәхнәләштерделәр. Тукайга багышланган шигырьләр укылды, җырлар җырланды. «Өзек кайсы шигырьдән?», «Рәсемне таны» уеннарында балалар бик актив булдылар, белемнәрен күрсәттеләр. Бәйрәмгә әкият персонажларының кунакка килүе тагын да ямь өстәде. Тукай китаплары туган якның матурлыгын, игелеген кадерләргә өйрәтә, мәрхәмәтле, гадел һәм кыю булырга өнди. Бәйрәм ахырында балалар татар халкының гимны булган «Туган тел » җырларын башкардылар.















### *« Туган тел »*

*И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!*
*Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.*

*Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,*
*Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.*

*И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,*
*Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.*

*И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:*
*Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!*





















## «Без Тукайны укыйбыз»



Габдулла Тукай "Туган тел"
Сибагатуллиннар гаиләсе




Габдулла Тукай "Сабыйга"
Гафуровлар гаиләсе



Габдулла Тукай "Бәйрәм бүген"
Шаһиевлар гаиләсе




Габдулла Тукай "Җир йокысы"
Җиһаншиннар гаиләсе



Габдулла Тукай
"Кошларга"
Сиражиевлар гаиләсе



Габдулла Тукай "Карлыгач"
Мөхетдиновлар гаиләсе



Габдулла Тукай "Ак бабай"
Асадуллиннар гаиләсе



Габдулла Тукай"Су анасы"
әкиятеннән өзек
Төхфәтуллиннар гаиләсе






Габдулла Тукай "Бишек
җыры" Исхаковлар гаиләсе



Габдулла Тукай "Су анасы" әкиятеннән өзек
Төхбәтуллинар гаиләсе




## «30 апрель - Янгын күзәтчелеге көне»

Тирә -якны ялмап алган көчле утка каршы көрәшүе бик авыр. Ярый әле бездә янгынга каршы көрәшүче курку белмәс, көчле, кыю, үз- үзен аямаучы кешеләр бар. Алар - янгын сүндерүчеләр. 30 апрель көнне балалар бакчасына «Янгын сүндерү бүлеге» хезмәткәре Хәкимуллин Азат Мөхтәр улы килде.Ул балаларга янгын куркынычсызлыгы турында сөйләде. Балаларның сорауларына җавап бирде,аларның сөйләгәннәрен тыңлады. Авыл җирлеге башлыгы Шакирова Ильфира Рамазан кызы да янгынны булдырмау буенча үзенең киңәшләрен бирде.Бик кирәкле,файдалы очрашу булды.












***Газетаны оештыручы һәм баш мөхәррир:*** *Шагиева А.К., , Галиуллина А.Ф.*
***Редколлегия әгъзалары***: *Гафурова Р.А.,Хөсәенова Р.Н., Гафурова Э.Р.*
*Адрес: 422018 ТР, Арча районы, Наласа авылы, Үзәк урам, 76 йорт*